КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 9 ноябрь г.Казань № 976

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының мәгариф оешмалары һәм спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә норматив чыгымнарны һәм хезмәт күрсәтүләр күләмнәрен раслау турында» 2023 ел, 06 сентябрь, 1089 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының мәгариф оешмалары һәм спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә норматив чыгымнарны һәм хезмәт күрсәтүләр күләмнәрен раслау турында» 2023 ел, 06 сентябрь, 1089 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 08 декабрь, 1580 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исеменә «Татарстан Республикасы шәһәр округлары» сүзләреннән соң «, дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләрен мәҗбүри башлангыч һәм даими психиатрия таныклаулары» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта:

икенче абзацка «Татарстан Республикасы шәһәр округлары» сүзләреннән соң «, дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләрен мәҗбүри башлангыч һәм даими психиатрия таныклаулары» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «хезмәт күрсәтүләр күләмнәре» сүзләрен «хезмәт күрсәтүләр күләмнәре нормативлары» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы шәһәр округлары» сүзләреннән соң «, дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләрен мәҗбүри башлангыч һәм даими психиатрия таныклаулары» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының мәгариф оешмалары һәм спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә норматив чыгымнарны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлгәннәр);

әлеге карар белән расланган 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының мәгариф оешмалары һәм спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә хезмәт күрсәтүләр күләмнәрен яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлгәннәр).

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 4 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 6 сентябрь, 1089 нчы карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 09 ноябрь, 976 нчы карары редакциясендә)

2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының мәгариф оешмалары һәм спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина караулары (тикшерүләрен), дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләрен мәҗбүри башлангыч һәм даими психиатрия таныклаулары үткәрүгә норматив чыгымнар

| Норматив чыгымнар исеме | Бер кешегә норматив чыгымнар, сум | | |
|---|---|---|---|
| | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Ир-ат җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле мәҗбүри медицина тикшерүләрен үткәрүгә чыгымнар | 1 853,31 | 1 927,44 | 2 004,54 |
| Ир-ат җенесендәге хезмәткәрләргә алдан мәҗбүри медицина тикшерүләрен үткәрүгә чыгымнар | 2 479,74 | 2 578,93 | 2 682,09 |
| 40 яшькә кадәрге хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле мәҗбүри медицина тикшерүләрен үткәрүгә чыгымнар | 2 313,07 | 2 405,59 | 2 501,81 |
| 40 яшькә кадәрге хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан мәҗбүри медицина тикшерүләрен үткәрүгә чыгымнар | 2 939,50 | 3 057,08 | 3 179,36 |
| 40 яшьтән арткан маммография узучы хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле мәҗбүри медицина тикшерүләрен үткәрүгә чыгымнар | 2 625,19 | 2 730,20 | 2 839,41 |
| 40 яшьтән арткан маммография узучы хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан мәҗбүри медицина тикшерүләрен үткәрүгә чыгымнар | 3 251,62 | 3 381,68 | 3 516,95 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 40 яшьтән арткан маммография узмаучы хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле мәҗбүри медицина тикшерүләрен үткәрүгә чыгымнар | 2 313,07 | 2 405,60 | 2 501,83 |
| 40 яшьтән арткан маммография узмаучы хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан мәҗбүри медицина тикшерүләрен үткәрүгә чыгымнар | 2 939,50 | 3 057,08 | 3 179,37 |
| Дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә алдан һәм әледән-әле мәҗбүри психиатрия тикшерүләрен үткәрүгә чыгымнар | 1 657,53 | | |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 6 сентябрь, 1089 нчы карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 09 ноябрь, 976 нчы карары редакциясендә)

2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының мәгариф оешмалары һәм спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен), дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләрен мәҗбүри башлангыч һәм даими психиатрия таныклаулары үткәрүгә хезмәт күрсәтүләр күләмнәре нормативлары

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү күләме нормативы, кеше | | |
|---|---|---|---|
| | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Ир-ат җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле мәҗбүри медицина каравы | 20 246 | 20 246 | 20 246 |
| Ир-ат җенесендәге хезмәткәрләргә алдан мәҗбүри медицина каравы | 756 | 756 | 756 |
| 40 яшькә кадәрге хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле мәҗбүри медицина каравы | 47 239 | 47 239 | 47 239 |
| 40 яшькә кадәрге хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан мәҗбүри медицина каравы | 1 764 | 1 764 | 1 764 |
| 40 яшьтән арткан маммография узучы хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле мәҗбүри медицина каравы | 44 540 | 44 540 | 44 540 |
| 40 яшьтән арткан маммография узучы хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан мәҗбүри медицина каравы | 1 665 | 1 665 | 1 665 |
| 40 яшьтән арткан маммография узмаучы хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле мәҗбүри медицина каравы | 22 945 | 22 945 | 22 945 |
| 40 яшьтән арткан маммография узмаучы хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан мәҗбүри медицина каравы | 857 | 857 | 857 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| Дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә алдан һәм әледән-әле мәҗбүри психиатрия тикшерүе | 81 237 | | |